СОВЕТ ПИЖМАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЫЖМАРА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«29» ноябрь 2024 ел № 113

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Пыжмара авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендәге муниципаль контроль хакындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

2024 елның 8 августындагы 289-ФЗ номерлы«Россия Федерациясе Һава кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге Советының 2024 елның 29 июлендәге 103 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.6.4 пунктында «66 статьясындагы 12 өлешендә» сүзләрен «66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләрендә» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 4.7.10 пунктында «66 статьясындагы 12 өлешендә» сүзләрен «66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләрендә» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 4.9.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.9.5. Күчмә тикшерү нәтиҗәләре буенча 4.2 пунктының 2 пунктчасында каралган карар кабул ителә алмый.».

2. Әлеге карарны рәсми рәвештә Татарстан Республикасының pravo.tatarstan.ru хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Пыжмара авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Пыжмара авыл җирлеге башлыгы өстенә йөкләргә.

Пыжмара авыл
җирлеге башлыгы Р.Х. Заляев